**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 12 ноябрендәге 3915 номерлы карары**

**2026 елда Казан шәһәрендә муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру турында**

2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы Федераль законның 9 һәм 40 статьяларын үтәү йөзеннән Казан шәһәрендә укучыларны белем бирү учреждениеләренә алып бару һәм алып кайтуны оештыру максатыннан **карар бирәм**:

1. Расларга һәм 2026 елда гамәлгә кертергә:

1.1. 2026 елга Казан шәһәрендә гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативларын (1 номерлы кушымта);

1.2. 2026 елга Казан шәһәрендә гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмәне (2 номерлы кушымта).

1.3. 2026 елга автобус маршрутлары исемлеген (3 номерлы кушымта).

2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (И.А.Ризванов) гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыруга бәйле чыгымнарны әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән нормативлар нигезендә, 2026 елга Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең бюджет исемлегендә каралган чаралар чикләрендә 0702 «Гомуми белем бирү» бүлеге, 0220242102 «Мәктәп

укучыларын йөртү буенча транспорт хезмәтләрен оештыру» максатчан статьясы буенча 94 051,9 мең сум күләмендә гамәлгә ашырырга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.И.Абзаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 12 ноябрендәге
3915 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**2026 елга Казан шәһәрендә гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары**

| Автотранспорт чарасының моделе | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | Бер автотранспорт чарасына ставка (бер елга, сумнарда) | Автотранспорт чарасы узган бер километр юлга ставка (сумнарда) |
| ГАЗ «Газель» | 1 446 420,70 | 18,17 |
| PEUGEOT BOXER | 1 454 465,00 | 12,88 |
| Ford Transit | 1 454 722,50 | 18,29 |
| Yutong | 1 560 726,61 | 35,14 |

_____________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 12 ноябрендәге
3915 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**2026 елга Казан шәһәрендә гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә 2026 елга Казан шәһәрендә гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү (алга таба – муниципаль хезмәт) бәясен исәпләү механизмын билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм хисап чорында автотранспорт чараларының фактта узган юлы нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда, автотранспорт чараларының фактта узган юлы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча хисап елында автотранспорт чарасы маршрутының расланган паспорты кысаларында автотранспорт чарасының фактта узган юлы буларак кабул ителә.

## II. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m)$$ , биредә:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ – m моделендәге автотранспорт чараларының фактта узган юлы (километрларда);

$NF_{km_m}$ – гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру бәясе нормативының бер километрга ставкасы (сумнарда);

$NF_{as\,m}$ – гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру бәясе нормативының бер автотранспорт чарасына ставкасы;

$M_m$ – m моделендәге автотранспорт чаралары саны (берәмлекләрдә);

$m$ – муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделенең номеры;

$k$ – муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.

---

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 12 ноябрендәге
3915 номерлы карарына
3 номерлы кушымта

## 2026 елга автобус маршрутлары исемлеге

<table>
<tr><th>№</th><th>Маршрут номеры</th><th>Мәктәп<br>(укучыларның килү урыны)</th><th>Торак пункт<br>(укучыларны җибәрү урыны)</th></tr>
<tr><td>1</td><td>1 ш</td><td>Казан шәһәре Вахитов районының «1 номерлы татар гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе</td><td>Иске Победилово торак массивы</td></tr>
<tr><td>2</td><td>2 ш-1</td><td rowspan="2">Казан шәһәре Киров районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 8 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе</td><td>Иске Аракчино торак массивы («Кичү» тукталышы)</td></tr>
<tr><td>3</td><td>2 ш-2</td><td>Красная Горка торак массивы (Вокзал урамы)</td></tr>
<tr><td>4</td><td>6 ш</td><td rowspan="5">Казан шәһәре Совет районының «П.А.Полушкин исемендәге 101 номерлы мәктәп – Мәгариф үзәге» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе</td><td>«Фәнни шәһәрчек» тукталышы</td></tr>
<tr><td>5</td><td>25 ш</td><td>Әки торак массивы</td></tr>
<tr><td>6</td><td>7 ш</td><td>Кече Дербышки торак массивы</td></tr>
<tr><td>7</td><td>16 ш</td><td>Колсәет торак массивы</td></tr>
<tr><td>8</td><td>17 ш</td><td>Чабакса торак массивы</td></tr>
<tr><td>9</td><td>9 ш</td><td>Казан шәһәре Совет районының «141 номерлы гимназия» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе</td><td>Колсәет торак массивы</td></tr>
<tr><td>10</td><td>22 ш</td><td>Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «60 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе</td><td>Борисоглебский торак массивы</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| 11 | 24 ш | Казан шәһәре Киров районының «В.А.Григорьев исемендәге аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 81 номерлы рус-татар урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Аракчино шоссесы («Кичү» тукталышы) |
| 12 | 27 ш | Казан шәһәре Совет районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 15 номерлы мәктәп» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Дербышки тороак массивы |
| 13 | 27 ш-1 | | «Ливадия» шифаханәсе (Луганск Халык Республикасы һәм Донецк Халык Республикасы балалары) |
| 14 | 79 ш | | 15 номерлы мәктәп – 110 номерлы лицей (Халитов урамы) |
| 15 | 28 ш | Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «5 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Краснооктябрьск торак массивы |
| 16 | 29 ш | Казан шәһәре Совет районының «11 номерлы татар гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Әки торак массивы |
| 17 | 30 ш | | Кече Дербышки торак массивы |
| 18 | 33 ш | Казан шәһәре Совет районының «22 номерлы мәктәп – Мәгариф үзәге» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Әки торак массивы |
| 19 | 35 ш | Казан шәһәре Киров районының «Татар телендә белем бирә торган 3 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Аккош күле микрорайоны |
| 20 | 36 ш | Казан шәһәре Киров районының «57 номерлы рус-татар урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Залесный торак массивы |
| 21 | 37 ш-1 | Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «147 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Крутушка торак массивы |
| 22 | 37 ш-2 | | Щербаково торак массивы («Ак Барс» кафесы» тукталышы) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 23 | 38 ш-1 | Казан шәһәре Мәскәү районының «130 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | «Тулай торак» тукталышы (Гудованцев урамы) |
| 24 | 38 ш-2 | | Новониколаевский торак массивы |
| 25 | 38 ш-3 | | Краснооктябрьск торак массивы |
| 26 | 40 ш-1 | Казан шәһәре Киров районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 151 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Тимерьюлчылар мәдәният йорты – Профилакторий (151 номерлы башлангыч мәктәп) |
| 27 | 40 ш-2 | | Профилакторий (151 номерлы башлангыч мәктәп) – 151 номерлы мәктәп (Бирюзовая урамы, 24 йорт) |
| 28 | 40 ш-3 | | Бирюзовая урамы – Профилакторий (151 номерлы башлангыч мәктәп) |
| 29 | 78 ш-1 | Казан шәһәре Идел буе районының «78 номерлы «Фарватер» лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (Ю.Фучик урамы, 40 йорт) | 3 нче Зеленая урамы |
| 30 | 78 ш-2 | | «Казан ярминкәсе» тукталышы |
| 31 | 78 ш-3 | | Восход урамы |
| 32 | 87 ш-2 | Казан шәһәре Идел буе районының «186 номерлы күппрофильле лицей – “Перспектива”» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (Рауис Гәрәев урамы, 117 йорт) | «Станция Спортивная» торак комплексы,<br>«Времена года» торак комплексы |
| 33 | 91 ш-1 | Казан шәһәре Совет районының «183 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Привольный торак массивы, Вишневка торак массивлары |
| 34 | 91 ш-2 | | Восточный торак массивы |
| 35 | 92 ш | Казан шәһәре Совет районының «156 номерлы мәктәп» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе<br><br>Казан шәһәре Совет районының «Татар телендә белем бирә торган 149 номерлы мәктәбе» | Привольный торак массивы – «Чишмәле» тукталышы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 36 | 93 ш | Казан шәһәре Идел буе районының «173 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе (Салмачы торак массивы, Мир урамы, 2А йорт) | Привольный торак массивы |
| 37 | 94 ш | Казан шәһәре Идел буе районының «Россия Герое Д.Р.Гыйлемханов исемендәге 42 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Привольный торак массивы |
| | | Казан шәһәре Идел буе районының «69 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| | | Казан шәһәре Идел буе районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә 24 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| | | Казан шәһәре Идел буе районының «Татар телендә белем бирә торган 18 номерлы гимназия – "Галәм"» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 38 | 94 ш-1 | Казан шәһәре Идел буе районының «69 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Тамчы урамындагы борылыш элмәге – Привольный торак массивы (микроавтобуслар өчен генә) |
| | | Казан шәһәре Идел буе районының «173 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | |
| 39 | 96 ш | Казан шәһәре Совет районының «183 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Иман урамы (Вознесенское торак массивы) |
| 40 | 96 ш-1 | | Вознесенское торак массивы |
| 41 | 102 ш | Казан шәһәре Киров районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 151 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Займище торак массивы |
| 42 | 105 ш | Казан шәһәре Совет районының «11 номерлы татар гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Чабакса торак массивы |
| 43 | 106 ш | Казан шәһәре Совет районының «185 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Самосырово торак массивы |
| 44 | 107 ш | Казан шәһәре Идел буе районының «133 номерлы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | «Времена года» торак комплексы, «Станция Спортивная» торак комплексы |
| 45 | 108 ш | Казан шәһәре Совет районының «95 номерлы “Икән” лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Вознесенское торак массивы |
| 46 | 109 ш | Казан шәһәре Мәскәү районының «99 номерлы мәктәп» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе | Икмәк заводы урамы |